КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 март г.Казань № 256

2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге эффективлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге эффективлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларын (алга таба – эффективлыкны бәяләү индикаторлары);

дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төбәк төрләре буенча контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең тиешле эшчәнлек өлкәсендә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне минимальләштерүдә чагыла торган төп күрсәткечләре исемлеген;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасындагы (алга таба – Система) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре хисаплары формаларына эффективлыкны бәяләү индикаторлары нигезендә үзгәрешләр кертергә;

хисап елына эффективлыкны бәяләү индикаторларының иң чик мәгънәләрен Системага кертүне, шулай ук анда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына беркетелгән эффективлыкны бәяләү индикаторларының факттагы мәгънәләрен актуаль хәлдә тотуны тәэмин итәргә;

хисап кварталыннан соң килә торган айның 20 есенә кадәр һәм 30 гыйнварга кадәр – IV квартал йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан индикаторларны үтәү мониторингы мәгълүматлары нигезендә эффективлыкны бәяләү индикаторларының һәр квартал буенча иң чик мәгънәләренә ирешү йомгаклары турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

2022 елның 1 апреленә кадәр, алга таба Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында карап тикшерү өчен, үткән елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан эффективлыкны бәяләү индикаторларының иң чик мәгънәләренә ирешү йомгаклары турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә:

эффективлыкны бәяләү буенча беркетелгән индикаторларның факттагы мәгънәләрен Системага кертүне һәм анда түбәндәгеләр буенча хисаплар бастырып чыгаруны тәэмин итәргә:

эффективлыкны бәяләүнең һәр квартал индикаторлары буенча – хисап кварталыннан соң килә торган айның 18 енә кадәр һәм 25 гыйнварга кадәр – IV квартал йомгаклары буенча;

эффективлыкны бәяләүнең еллык индикаторлары буенча – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган сроклар нигезендә;

агымдагы елның 25 декабренә кадәр агымдагы елга эффективлыкны бәяләүнең беркетелгән индикаторларын бәяләү мәгънәләрен һәм планлаштырыла торган өч елга әлеге индикаторларның иң чик мәгънәләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә;

Системадагы мәгълүматларны актуальләштерергә кирәк булганда, регламент срогыннан соң бу турыда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына хәбәр итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре өчен эффективлыкны бәяләү индикаторларын исәпләп чыгаручы һәм аларның мәгънәләрен Системага кертүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы министрлыкларына Системага хисап кварталыннан соң килә торган айның 16 ысына кадәр эффективлыкны бәяләүнең һәр квартал индикаторлары буенча һәм 18 гыйнварга кадәр – IV квартал йомгаклары буенча факттагы мәгънәләрне кертүне тәэмин итәргә.

5. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) функцияләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына бу карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан гамәлгә ашыра торган контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге нәтиҗәлелеген

һәм эффективлыгын бәяләү тәртибендә билгеләнгән таләпләргә таянып эш итәргә.

6. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

эффективлыкны бәяләү индикаторлары үтәлешен бәяләү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, эффективлыкны бәяләү индикаторларының иң яхшы мәгънәләренә ирешкәннәре өчен бүләкләү максатларында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләрен стимуллау турында карар кабул итәргә хокуклы;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең һәр квартал рейтингын формалаштырганда, эффективлыкны бәяләү индикаторлары үтәлеше процентын исәпләп чыгарганда аларның авырлыгы тигез дип санала;

эффективлыкны бәяләүнең еллык индикаторлары буенча фактагы мәгънәләр хисап чорыннан соң килә торган II кварталга мәгълүматларны бәяләгәндә исәпкә алына;

хисап чоры өчен эффективлыкны бәяләүнең һәр квартал индикаторлары буенча мәгълүматы булмаган фактагы мәгънәләр киләсе кварталда мәгълүматларны бәяләгәндә исәпкә алына;

хисап бастырып чыгарыла торган датага эффективлыкны бәяләү индикаторлары буенча статистик мәгълүматлар булмаган очракта, хисап формасына киләсе хисап чорында фактагы мәгънәләрне алга таба кертеп, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органын бәяләү мәгълүматлары кертелә.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына бер ай эчендә эффективлыкны бәяләү индикаторлары мәгънәләренә туры китерү өлешендә дәүләт программалары күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

8. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2021 ел, 25 март, 166 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 18 октябрь, 977 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2021 ел, 25 март, 166 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 18 декабрь, 1195 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Респуб-

ликасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2021 ел, 25 март, 166 нчы карары белән расланган 2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 февраль, 94 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2021 ел, 25 март, 166 нчы карары белән расланган 2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 2 март, 190 нчы карары.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин